Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Бураково авыл җирлеге Советы

КАРАР

№18-4 07.06.2021 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Бураково авыл җирлеге Советы депутатларының ачык утырышларында гражданнарның (физик затларның) булуын тәэмин итү тәртибен раслау турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Бураковока авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Бураково авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Бураково авыл җирлеге советы депутатларының ачык утырышларында гражданнарның (физик затларның) булуын тәэмин итү Тәртибен расларга.
2. Бураково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Чын карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Бураково авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мингалиев.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Бураково авыл җирлеге Советының 07.06.2021 елның18-4 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Бураково авыл җирлеге советы депутатларының ачык утырышларында гражданнарның (физик затларның) булуын тәэмин итү тәртибе

1. Әлеге тәртип «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 2 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Бураково авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

2. Гражданнарга (физик затларга) советның ачык утырышларында катнашу мөмкинлеге гарантияләнә. Гамәлдәге закон таләпләренә туры китереп ябык дип игълан ителгән утырышлар һәм аерым мәсьәләләр искәрмә булып тора.

3. Совет утырышын уздыру датасын, вакытын һәм урынын игълан итү ул башланганчы 5 көннән дә соңга калмыйча, бу хакта мәгълүматны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән башкарыла, моңа Советның чираттан тыш утырышлары керми.

4. Гражданнар (физик затлар) Советының ачык утырышларында катнашу, гражданин катнашырга теләгән Совет утырышы датасын, шулай ук фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшәү урыны адресын, шәхесен ачыклаучы документның сериясен һәм номерын күрсәтеп, язма гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Утырышта катнашучылар алдында белдерелгән гражданнар исемлеге утырыш көнендә Совет бинасына кергәндә саклау постына тапшырыла. Исемлектә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

- гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме.

6. Гражданнарны теркәү шәхесен таныклый торган документ күрсәтелгәндә уздырыла.

7. Алкоголь, наркотик яисә токсик исереклек халәтендәге гражданнар, җәмәгать тәртибен боза торган гражданнар, шулай ук шәхесне таныклый торган документны күрсәтүдән баш тарткан гражданнар Совет утырышына рөхсәт ителми.

8. Гариза биргән гражданнар Совет тарафыннан көн тәртибендәге расланганнан соң утырыш залына чакырыла.

9. Гражданнар утырышлар залына утырышлар секретаре чакыруы буенча уза һәм алар өчен махсус билгеләнгән урыннарда урнаштырыла.

10. Җәмәгать тәртибен бозган очракта хокук бозучылар рәислек итүче таләбе буенча утырыш залыннан чыгарыла.

11. Депутатлар Советының ябык утырышын гамәлдәге законнар нигезендә уздыру турында карар кабул ителгән очракта, гражданнар утырышны уздыру залына кертелми.